БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«12» 01 2023 ел № 9

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт эшчәнлеге тәртибен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Күмү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы федераль законнар нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставына таянып, җирләү эше өлкәсендә муниципаль хокукый актларны камилләштерү максатларында, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт итеп «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының хуҗалык-эксплуатация хезмәте» муниципаль бюджет учреждениесен билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт эшчәнлеге тәртибен кушымта нигезендә расларга.

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» интернет - ресурсында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче А.Ф. Хәйретдинов

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитетының
2022 елның «12» 01
9 номерлы карарына
кушымта

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт эшчәнлеге тәртибе

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт эшчәнлегенең әлеге тәртибе (алга таба - Тәртип) үлгәннәрнең (һәлак булганнарның) мәетләрен (җәсәдләрен) күмүгә (күчереп күмүгә) бәйле мөнәсәбәтләрне тулы күләмдә җайга сала.

2. Махсуслаштырылган хезмәт үз эшендә «Күмү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, «Мәрхүмнәрне күмү буенча хезмәтләр күрсәтү гарантияләре турында» Россия Федерациясе Президентының 1996 елның 29 июнендәге 1001 номерлы Указы белән җитәкчелек итә.

3. Җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт бурычлары түбәндәгеләр:

- Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы халкына һәркем файдалана алырлык ритуаль хезмәт күрсәтүне тәэмин итү, аңа күмү буенча хезмәт күрсәтүләрнең гарантияләнгән исемлеге керә;

- билгеләнгән үрнәктә күмү турында таныклык булган очракта, мәрхүмнәрнең традицияләргә, гореф-гадәтләргә туры китереп дини зиратларда, тугандаш каберлекләрдә күмелү турында белдергән ихтыярын үтәүне тәэмин итү;

- күмү буенча хезмәтләргә заказлар кабул итү һәм аларны үтәү буенча документларның архив фондын булдыру һәм аларның сакланышын тәэмин итү;

- тиешле хезмәтләрне сыйфатсыз башкарган очракта, җитешсезлекләрне үз көчләре белән һәм үз хисабына бетерү;

- гражданнарга гарантияләнгән исемлек чикләрендә күмү буенча хезмәтләр күрсәтү тәртибе һәм шартлары турында, шулай ук гамәлдәге законнар нигезендә башка хезмәтләр турында мәгълүмат җиткерү;

- эшләр башкаруның куркынычсызлык кагыйдәләрен, санитар-гигиена

нормаларын һәм кешеләрнең сәламәтлеген яклау таләпләрен үтәү.

4. Күмү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясе, Татарстан Республикасы буенча Россия Федерациясе Пенсия фондының тиешле бүлекләре, Россия Федерациясе социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча төбәк бүлеге, Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты белән килештеп, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты тарафыннан билгеләнә.

5. Махсуслаштырылган хезмәт әлеге Тәртиптә билгеләнгән таләпләр нигезендә үлгән гражданнарны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының җәмәгать зиратларында күмү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлегендәге хезмәтләрне күрсәтә.

6. Мәрхүмне җирләү бурычын үз өстенә алган ир яисә хатынга, якын туганнарына, башка туганнарына, законлы вәкиленә яисә башка затка күмү буенча хезмәтләр күрсәтү исемлегендәге түбәндәге хезмәтләрне түләүсез нигездә күрсәтү гарантияләнә:

- күмү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү;

- гәүдәне каплау (кафенләү);

- табутны һәм күмү өчен кирәкле башка предметларны бирү һәм китерү;

- мәрхүмнең гәүдәсен (җәсәден) Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә урнашкан зиратка китерү;

- күмү (кабер казу һәм җирләү).

7. Мәрхүмнең ире яисә хатыны, якын туганнары, башка туганнары яисә законлы вәкиле булмаганда яисә алар тарафыннан күмүне гамәлгә ашыру мөмкин булмаганда, шулай ук аның шәхесен эчке эшләр органнары билгеләгәннән соң күмүне гамәлгә ашыру бурычын үз өстенә алган башка затлар булмаганда, Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса, үлем сәбәбен ачыклаганнан соң өч тәүлек эчендә махсуслаштырылган хезмәт тарафыннан гамәлгә ашырыла.

8. Шәхесе Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вакытта эчке эшләр органнары тарафыннан билгеләнмәгән мәрхүмнәрне күмү әлеге органнар ризалыгы белән махсуслаштырылган хезмәт тарафыннан Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җәмәгать зиратларының мондый очраклар өчен билгеләнгән урыннарында гүргә иңдерү юлы белән гамәлгә ашырыла.

9. Мәрхүмне күмүне үз өстенә алган затның теләге буенча

махсуслаштырылган хезмәт, күмү буенча хезмәт күрсәтүләрнең гарантияләнгән исемлегеннән тыш, түләүле нигездә хезмәт күрсәтергә мөмкин.

10. Махсуслаштырылган хезмәт хезмәткәрләре махсуслаштырылган хезмәттән ритуаль хезмәтләрне, шул исәптән күмү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлегенә кергән түләүле хезмәтләрне алуны йөкләргә (мәҗбүр итәргә) хокуклы түгел.

11. Күмү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлегендәге хезмәтләр түбәндәге адрес буенча мөрәҗәгать иткән көнне махсуслаштырылган хезмәт хезмәткәре тарафыннан гамәлгә ашырыла: Балтач ш.т.п., Ленин ур., 3 нче йорт.

12. Махсуслаштырылган хезмәт хезмәткәре махсуслаштырылган хезмәткә мөрәҗәгать иткән затка консультатив ярдәм күрсәтә:

- күмү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлегендәге хезмәтләрне күрсәтү тәртибе буенча;

- зиратларның эш кагыйдәләре буенча;

- күмү һәм җирләү эше өлкәсендә Россия Федерациясе законнары нигезендә гражданнарга түләнә торган күмүгә социаль пособие һәм бер тапкыр бирелә торган матди ярдәм күрсәтү тәртибе һәм күләме буенча.

13. Күмү буенча хезмәт күрсәтүнең гарантияләнгән исемлегендәге хезмәтләрне алу өчен мөрәҗәгать итүчегә махсуслаштырылган хезмәткә гамәлдәге законнарда билгеләнгән документларны тапшырырга кирәк.

14. Махсуслаштырылган хезмәт хезмәткәре күмү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерә, йолалар һәм традицияләр, шулай ук мәрхүмнең дине нигезендә күмү датасын һәм вакытын билгеләп куя. Документларны рәсмиләштерү нәтиҗәләре буенча махсуслаштырылган хезмәт әлеге Тәртипнең 6 пункты нигезендә күмү буенча хезмәтләр күрсәтә.

15. Махсуслаштырылган хезмәттә түбәндәгеләр булырга тиеш:

- милек хокукында, арендалау хокукында яисә башка законлы нигездә махсус җиһазландырылган, күмү буенча хезмәтләр күрсәтүгә заказлар кабул итүнең тиешле шартларын тәэмин итә торган биналар;

- хезмәтләр күрсәтү өчен махсуслаштырылган транспорт;

- хезмәтләр күрсәтү өчен персонал;

- туры телефон элемтәсе;

- түбәндәге мәгълүмат белән элмә такта: оешманың исеме, аның кайда булуы (юридик адресы), шулай ук эш режимы.

16. Махсуслаштырылган хезмәтнең күмү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлегендәге хезмәтләрне күрсәтүгә заказлар кабул итә торган бинасында күрү өчен уңайлы булган урында түбәндәге мәҗбүри мәгълүмат булырга тиеш:

«Күмү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон;

- «Мәрхүмнәрне күмү буенча хезмәтләр күрсәтү хокукларын гарантияләү турында» 1996 елның 29 июнендәге 1001 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указы;

- «Кулланучылар хокукларын яклау турында» 1992 елның 7 февралендәге 2300-1 номерлы Россия Федерациясе Законы;

- күмү буенча хезмәт күрсәтүләрнең гарантияләнгән исемлеге;

- күмү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлегеннән тыш күрсәтелә һәм бирелә торган ритуаль хезмәтләргә һәм ритуаль әйберләргә прейскурант (әгәр мондый хезмәт күрсәтелсә);

17. Җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт түбәндәге хокукларга ия:

- билгеләнгән тәртиптә йөкләнгән бурычларны үтәү өчен кирәкле матди-техник база сатып алырга яисә арендаларга;

- күмүгә заказлар кабул итү пунктларын, ритуаль әйберләр сату кибетләре эшен оештырырга;

- күмү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр хакын кайтарырга;

- гамәлдәге законнарга каршы килмәсә, үзенә йөкләнгән бурычларны үтәүгә башка оешмаларны яисә шәхси эшкуарларны җәлеп итәргә.

18. Күмү һәм җирләү эше өлкәсендә Россия Федерациясе законнары таләпләрен үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән өчен махсуслаштырылган хезмәт гамәлдәге законнар нигезендә җаваплы.

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт эшчәнлеге тәртибенә кушымта
(Форма)

«Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының хуҗалык-эксплуатация хезмәте» МБУ директоры
Ф. Х. Сибагатуллинга
______________________________
______________________________
______________________________,
адрес:__________________________
______________________________,
тел.___________________________

Гариза

Сездән «Күмү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы №8-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясы нигезендә, __________________________________________________ адресы буенча теркәлгән мәрхүм ________________________________________ ____________________ күмү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлегендәге хезмәтләрне түләүсез нигездә күрсәтүегезне сорыйм.

Кушымта:

_________________
(имза)

«____»____________20____ ел